**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2089**
**30.04.2020**

2020 елда су коену сезонына шәһәр халкының массакүләм ял итү урыннары әзерлеген тәэмин итү турында

Су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү, аларның тормышын һәм сәламәтлеген саклау буенча чараларны гамәлгә ашыру, шәһәр халкының массакүләм ялы өчен шартлар тудыру һәм массакүләм ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы Карары, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларын шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлар өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2008 елның 25 сентябрендәге 34/14 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Расларга:

1) шәһәр территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү буенча комиссия составын, 1 нче кушымтада каралганча;

2) 2020 елда су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү буенча чаралар планын, 2 нче кушымтада каралганча.

2. Су коену сезоны срокларын һәм су объектларының рекреация зоналары эшенең дәвамлылыгын 2020 елның 1 июненнән 2020 елның 31 августына кадәр дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов